## 18. Татар телем – якты йолдызым

Татар теле, якты йолдыз булып,
Юл күрсәтә дөнья күгендә.
Минем җырым – телемә мәдхия,
Җырлыйм аны туган телемдә.
Кушымта: Татар телем, балкый йолдыз булып,
Тиң булмас аңа башкасы.
Горурланам туган телем белән,
Мин бит татар, татар баласы.
Бишек җыры ят булмады миңа,
«Әни» диеп телем ачылган,
Татар телем, бирдең очар канат,
Хәзер биекләргә оча алам.
Кушымта.
Халкыбызның мирасларын ачтың,
Тарихны да әйбәт беләбез,
Телебезне саклау – намус эше.
Мәңге яшә татар телебез!